# КОРБАН

www.darul-kutub.com

Хузур 1435/2014
Казан

УДК 297
ББК 86.38

Корбан. - Казан: Хузур, 2014. - 32 б.

Одобрено к печати решением № 14–18
Экспертного совета ЦРО - ДУМ РТ

Отпечатано в соответствии с предоставленным электронным
материалом в типографии «Зур Казан»

Подписано в печать 12.09.2014.
Формат 60Х90/16 Печать офсетная. Усл. печ. листов 2
Заказ № 52. Тираж 2000.
Издательсто «Хузур-Спокойствие».
Адрес: 420111 г. Казань, ул. Лобачевского, 6.

www.darul-kutub.com

بِسْمِ اللهِ الرَّحْمٰنِ الرَّحِيمِ

# МОКАДДИМӘ
# КОРБАННЫҢ МӘГЪНӘСЕ ҺӘМ ТАРИХЫ

Гыйбадәт — адәм баласының ихтыяҗлары арасында иң мөһиме, тик ихлас гыйбадәт ярдәмендә генә ул рухи камиллеккә ирешә ала. Гыйбадәттән ерак торган кешеләр исә, еш кына, күңелләре кыйналып, җаннарына тыңгы таба алмый йөриләр. Рухи камиллек юлына аяк басып, төрле-төрле мәшәкать вә хәсрәтләр аша уза-уза гөнаһ керләреннән арынган бәндәләр, бәхет-сәгадәткә ирешеп, җан тынычлыгы табып диндар гомер кичерәләр. Андыйларны фани дөньяның дәһшәтле чоңгыллары бервакытта да үзләренә тартып, һәлак итә алмас.

Һәрбер адәм баласы рухи ихтыяҗларына дәрман табып, Раббысына шөкер итүче кол, илаһи канун-кагыйдәләргә итагатьле бәндә булып яшәсен өчен, Аллаһы тәгалә кешеләргә кайбер гыйбадәтләрне ваҗиб кылган. Тик ул гыйбадәтләр шифалы дару кебек, табиб киңәшләрен сүзгә-сүз тоткан вакытта гына дәвалаучы хасияткә ия. Намаз, ураза, зәкят һәм хаҗ кебек асыл гыйбадәтләр белән янәшә, Аллаһы тәгаләнең фазыл-рәхмәте вә ризалыгына ирешеп, Аңа якынрак булу өчен билгеләнгән кайбер башка гыйбадәтләр дә бар. Шундыйларның берсе — корбан.

«Корбан» сүзе изге Коръән китабыннан алынган. Аның тамыры гарәпнең «карубә» — «якынаю» фигыленә барып тоташа. Шулай итеп, «корбан» — нәрсәгә дә булса якынаю, дигән мәгънәне аңлата булып чыга. Диндә бу «якынаю»дан максат бер генә — Аллаһының рәхмәтенә ирешү. Моның өчен, мөселман кешесенә үзен, малын вә җанын Хак Тәгаләгә багышлау шарт. Аның корбан чалуы да, ахыр чиктә, Раббысының боерыгын үтәү максаты белән генә булыр. Корбан бәйрәменең асылын адәм баласының Аллаһы әмеренә буйсынуын реаль

www.darul-kutub.com

гамәл белән исбатлавы тәшкил итә. Корбан итеп китерелергә тиешле әйберне дә Аллаһы тәгалә үзе билгеләп куйган, ул да булса — махсус шартларга ия булган хайван. Бөек Раббыбыз үзенең сөекле бәндәсе Ибраһим пәйгамбәрнең, буйсыну вә итагать сынавы буларак, корбан ителергә тиешле булган газиз улын махсус хайванга — куй тәкәгә алыштырган. Бу кыйсса барчаларыбызга да яхшы мәгълүм.

Ибраһим пәйгамбәрне Раббысы тугрылык сынавы аша уздырырга карар кыла. Башта ул малы белән сынала: Аллаһы тәгалә аңа «Аллаһы» сүзен әйткән һәрбер кешегә байлыгын өләшергә боера. Шул рәвешле, Ибраһим пәйгамбәр тора-бара кулындагы барча мөлкәтне таратып бетерә, ләкин ахырдан Аллаһы тәгалә аңа малын бик күп мәртәбәләр арттырып кайтарып бирә. Соңыннан, Хак Тәгаләнең бу тугры бәндәсе үз җаны белән имтиханга тартыла. Ул бу юлы да, Раббысы хакына, мәҗүси кавемдәшләре ташлаган учакта янып үләргә әзер булуын исбатлый. Аллаһы тәгалә аның бу фидакарьлеген дә кабул итә, һәм дөрләп янган ялкын телләрен хуш исле гөлбакчага әверелдерә. Ниһаять, шәфкатьле пәйгамбәрнең тугрылыгы үз якыннары аркылы сынала. Картаймыш көнендә Раббысы аңа бер угыл бирә. Ибраһим галәйһиссәлам аны үз җаныннан да артык күрә. Улы да бу мәхәббәткә хөрмәт һәм олылау белән җавап кайтара. Ләкин хак төшләр аркылы Раббысы Ибраһим пәйгамбәргә бәгырь җимешен корбан итәргә кирәклеген белдерә. Йокыдан торуга, мәрхәмәтле ата төшен улына сөйләп бирә. Улы исә, атасының сөйләвен сабыр гына тыңлап бетергәннән соң, итагать вә тәслимиятнең иң камил үрнәген күрсәтә. Изге китабыбыз Коръәндә бу хакта болай диелә: «Ул әйтте: «И улым! Төшемдә сине бугазлавымны күрдем. Бу хакта ни әйтерсең?» (Угылы) әйтте: «И әтием! Сиңа ни боерылган булса, шуны кыл. Аллаһы теләсә, мине сабырлык кылучылардан табарсың». (Саффәт сүрәсе, 37/102). Ата белән угыл билгеләнгән урынга килеп җиткәннән соң, Ибраһим галәйһиссәлам улын корбан китерү нияте белән җиргә яткыра. Коръәндә бу хакта тәбәндәгеләрне укыйбыз: «(Ата белән угыл) икесе дә Хак әмеренә ризалык күрсәтеп, Ибраһим улын йөзтүбән яткыргач, Без: «Әй Ибраһим! Тәхкыйк, төшеңне

www.darul-kutub.com

расладың» — дип нида кылдык. Дөреслектә, без изгелек кылучыларны шулай бүләклибез. Бу ачыктан-ачык бер сынаудыр. Инде Без аны олы бер корбан белән йолып алдык». (Саффәт сүрәсе, 37/103–107). Шул рәвешле, Аллаһы тәгалә аның тугрылыгын кабул итә һәм улы урынына корбан итәргә дип күкләрдән бер тәкә иңдерә. Бәс, безнең дә чалган корбаннарыбыз Хак Тәгаләгә тугрылыгыбызның бер дәлил вә исбатыдыр.

Корбан — үзең өчен аерата кадерле булган нәрсәне Аллаһыга багышлаудыр. Илаһи рәхмәт ошбу корбанны, итен мохтаҗларга тарату мөстәхәб булган, хайван белән алыштырган. Моның хикмәтен бигрәк тә авыл җирендә яшәүчеләр, тырышып-кадерләп үстергән малкайларын Аллаһы ризалыгы өчен чалган тәкъва мөселманнар яхшы аңлый булса кирәк. Күңелен кызгану хисе биләп алса да, ул Аллаһы тәгалә әмеренә хилафлык кылмас. Хак Тәгалә «Корбан чал!» дип боерган икән, адәм баласы бу әмергә буйсынып, үзе өчен кадерле булган әйберен корбан итәргә тиеш. Чөнки Аллаһының фәрманы бар нәрсәдән өстендер.

Корбан — бик борынгы заманнардан килгән гыйбадәт. Аллаһыга якынайтучы гыйбадәт буларак, корбан төшенчәсе булмаган бер генә дин дә юктыр, мөгаен. Аның башы Адәм галәйһиссәлам чорына ук барып тоташа. Изге Коръәндә Адәм пәйгамбәрнең ике улы Кабил белән Һабилнең корбан чалу кыйссасы бәян ителә: «Аларга Адәмнең ике угылының хәбәрен хаклык белән ирештер. Менә алар икесе дә корбан китерде, берсенеке кабул ителде, ә икенчесенеке исә кабул ителмәде» (Маидә сүрәсе, 5/27). Бу вакыйганың асылы шуннан гыйбарәт: ике бертуган арасында гауга кубып, мәсьәләнең хәл ителүе өчен икесеннән дә корбан сорала. Кемнеке Аллаһы тарафыннан кабул кылынса, шул — хаклы. Көтү көтеп көн күргән Һабил корбанлыкка иң кадерле малын — симез тәкәне куя. Иген игеп, шактый мая тупларга өлгергән Кабил исә корбанга дип сәләмә генә бер бодай көлтәсен китереп сала. Кабилнең корбаны кабул ителми…

www.darul-kutub.com

# КОРБАННЫҢ ХИКМӘТЕ ҺӘМ ФАЙДАЛАРЫ

1. **Халык арасында бердәмлек һәм ярдәмләшү хисләрен көчәйтә:**

Динебездә килгән барча гыйбадәтләрдә аерым-аерым һәрбер кеше өчен дә, гомум җәмгыять өчен дә олы файдалар бар. Мисалга намазны алыйк. Бу гыйбадәт, бер яктан, адәм баласына Аллаһыга кол булуның асыл мәгънәсенә төшенергә ярдәм итсә, икенче яктан, Коръән сүзләре белән әйткәндә, кешене һәртөрле бозыклык вә тыелган эшләрдән саклап тора. Шулай ук, гыйбадәтнең башка төрләре дә, әйтик, ураза, зәкят, хаҗ кебекләр, кеше шәхсиятенә бихисап фазыйләтләр өстәү белән бергә, җәмгыятьтә тотрыклылык һәм бердәмлек булдырырга ярдәм итәләр. Мөселманнарның төп ике бәйрәменең берсе булган Корбан гаете көннәрендә чалынган хайваннар нәкъ менә шул макстака юнәлгән. Корбан чалган кеше гыйбадәт савабы алу өстенә, мескен-фәкыйрьләргә дә хәл кадәре ярдәмен җиткереп, җәмгыятьнең бердәмлеген куәтләүгә үзеннән өлеш кертә.

2. **Корбан гыйбадәте адәм баласын Раббысына якынайта:**

Кеше бик тә онытучан һәм гафиллеккә тартым итеп яратылган. Шуңа да ул малы, балалары, гомумән, бу фани дөньядагы барча мөлкәтенең асыл хуҗасы булган Затны еш кына онытып җибәргәли. Бу исә, үз чиратында, анда тәкәбберлек һәм масаючанлык кебек сыйфатларның уянуына китерә. Корбан исә адәм баласына барча мәхлукатның асыл хуҗасы кем икәнлеген искәртә. Шулай ук, аңа бирелгән гомум нигъмәтләрнең Аллаһының рәхмәт әсәре булуын аңларга мәҗбүр итә. Мондый кешенең тора-бара йөрәгендә Раббысына карата шөкер хисләре уяна. Аллаһы ризалыгына илтүче юл да шуннан башлана.

3. **Корбан — кешенең тәкъвалык билгесе**

Корбан кешенең Илаһи әмерләрне үтәүдәге ихласлыгын чагылдырып, аның тәкъвалык дәрәҗәсен күрсәтеп килә. Корбан гыйбадәте ярдәмендә Аллаһы тәгалә колларының тәкъвалык мәртәбәсен сыный, Илаһи әмерләрне үтәүгә

әзерлек дәрәҗәләрен имтихан кыла. Коръәндә бу хакта: «Аларның (корбанлык хайванның) ите дә, каны да Аллаһыга ирешмәс, Аңа фәкать сезнең тәкъвалыгыгыз гына барып ирешер», (Хаҗ сүрәсе, 22/37) — диелә. Икенче бер аяттә исә: «Менә шулай! Кемдә-кем Аллаһының шигарьләрен (диннең ачык галәмәте булган гыйбадәтләрне) зурласа, бу аның кальбендәге тәкъвалыктан килә» (Хаҗ 22/32),— дип боерыла.

4. **Корбан гыйбадәте безгә Аллаһы боерыгына буйсынуның Ибраһим һәм Исмәгыйль пәйгамбәрләр тормышында дастани югарылыкка ирешкән мисалын искәртә:**

Алдарак та искәртелгәнчә, күп гасырлар буена яшәп килгән бу күркәм йоланың чишмә башында Аллаһының бөек илчесе вә расүле булган Ибраһим галәйһиссәламнең торганын күрәбез.

Әбү Һурайра (радыйәллаһу гәнһү) сүзләренә караганда, хәзрәте Ибраһим иң бөек биш пәйгамбәр җөмләсеннән.

Изге Коръәндә килгән кыйссадан (Әнгам сүрәсе, 6/76) без Ибраһим галәйһиссәламнең үткен зиһенле, мөшрикләргә каршы торудан гаҗәеп чыдам һәм кыю, хөр вә какшамас иманлы, көферлекнең иң кечкенә галәмәтләреннән дә пакь кеше булуын укып беләбез.

Әлеге кыйсса могътәбәр галимнәребезнең тәфсир китапларында болайрак тасвир кылына: пәйгамбәрлек вазыйфасын үтәү барышында, Ибраһим пәйгамбәр мөшрикләрне ялгыш инануларыннан кире чигенергә, барча мәхлүкатны юктан бар кылган һәм тәрбия кылып торган Аллаһыдан гайре кемне яки нәрсәне дә булса илаһ итеп тотудан тыеларга чакыра. Ул аларның акылларына мөрәҗәгать итеп, «үзе дә юктан бар кылынган нәрсә ничек инде илаһ була алсын?» дигән сорау куя. Берсендә ул җем-җем килеп торган йолдызга ишарәләп: «Шушы мени инде минем Раббым?» дип оран сала. Ә бу йолдыз сүнеп, күк гөмбәзендә күренмәс булуга, үз соравына үзе җавап биргәндәй: «Үзгәреп, алышынып торган нәрсә һичничек илаһ була алмый. Чөнки үзгәреп тору — мәхлүкатка хас сыйфат. Ә Аллаһы исә — мәңгелек, Аның сыйфатлары да мәңге үзгәрешсез»,— дип нәтиҗә ясый.

Коръәндә Аллаһы тәгалә үзенең сөекле илчесе Ибраһим галәйһиссәламгә туры юлны (Әнбия сүрәсе, 21/51) күрсәтүе һәм аның мөшрикләр җөмләсеннән булмавы (Бәкара сүрәсе, 2/135) хакында бәян итә.

Хак Тәгалә Ибраһим пәйгамбәрнең иманын куәтләр өчен, аңа сынау арты сынау җибәреп тора. Шәфкатьле пәйгамбәр, Илаһи фәрманга буйсынып, үз угылы Исмәгыйльне корбан итәргә тиеш була. Бу боерыкны җиренә җиткереп үтәү ниятеннән, Ибраһим пәйгамбәр Аллаһы тәгалә буйсынуның тиңсез үрнәген күрсәтә. Сабый баланың каны түгелүне теләмәгән Раббыбыз Ибраһим галәйһиссәламнең корбанын ниятенә карап кабул итә, ә корбанга Исмәгыйль урынына куй тәкәсе чалына.

**5. Корбан — Аллаһы биргән исәпсез-хисапсыз нигъмәтләргә шөкер итү билгесе**

Аллаһы тәгалә безне иге-чиге булмаган нигъмәтләр белән уратып алган, аларның барысы да бездән шөкер итүне сорый. Корбан гыйбадәте исә шөкернең иң ачык чагылышларының берсе. Аллаһы тәгалә Коръәндә: «Без корбанлык дөяләрне сезнең өчен Аллаһының шигарьләре иттек. Аларның сезгә файдасы бар. Бәс, алар сафлар хәлендә тезелеп торганда, өсләрендә Аллаһының исемен телгә алыгыз. Ә инде бугазлап җиргә аударганнан соң, итләрен ашагыз һәм азга канәгать кылып яшәүчеләр белән мохтаҗлык сәбәпле соранучыларга ашатыгыз. Без аларны шул рәвешле сезгә буйсындырдык, шаять ки, шөкер итүчеләрдән булырсыз». (Хаҗ сүрәсе, 22/36)

**6. Корбан — гөнаһлардан арыну һәм гыйбадәтне кимчелекләрдән пакьләү чарасы:**

Аллаһы рәсүле (салләллаһу гәләйһи үә сәлләм) кызы Фатыймага эндәшеп, болай дигән: «Әй Фатыйма! Чалган корбанлыгың янында басып тор. Шуны бел: аның җиргә тамган беренче тамчы каны белән үк синең гөнаһларың ярлыканыр». (Хәким, Һәйсәми, Бәйһакый)

www.darul-kutub.com

# КОРБАН СҮЗЕНЕҢ МӘГЪНӘСЕ, КОРБАННЫҢ ШӘРИГАТЬТӘГЕ ХӨКЕМЕ ҺӘМ АҢА КАГЫЛЫШЛЫ КАЙБЕР ФИКЪҺИ МӘСЬӘЛӘЛӘР

## 1. «Корбан» сүзенең мәгънәсе һәм шәригатьтәге хөкеме:

Корбан — мөэмин-мөселман кешесе тарафыннан билгеле бер вакытта, Аллаһы ризалыгына ирешү нияте белән кылынган гыйбадәтнең бер төредер. Корбанлыкка дөяләр, эре һәм кече мөгезле терлекләрнең һәркайсысы яраклыдыр. Корбан дип, чалынган хайванга да әйтеләдер.

Корбан гыйбадәте зәкят һәм гает намазлары белән бер вакыттарак, һиҗрәтнең икенче елында ваҗиб кылынган. Бу хакта катгый Коръән аятләре, сахих хәдисләр һәм иҗмаг (галимнәрнең бердәм карары) бар.

Коръәндәге дәлилләр ошбулардыр: «Бәс, Раббың ризалыгы өчен намаз кыл һәм корбан чал!» (Кәүсәр сүрәсе, 108/2), «Без корбанлык дөяләрне сезнең өчен Аллаһының шигарьләре иттек. Аларның сезгә файдасы бар. Бәс, алар сафлар хәлендә тезелеп торганда, өсләрендә Аллаһының исемен телгә алыгыз. Ә инде бугазлап җиргә аударганнан соң, итләрен ашагыз һәм азга канәгать кылып яшәүчеләр белән мохтаҗлык сәбәпле соранучыларга ашатыгыз. Без аларны шул рәвешле сезгә буйсындырдык, шаять ки, шөкер итүчеләрдән булырсыз» (Хаҗ сүрәсе, 22/36).

Сөннәттә дә дәлилләр бихисап. Шундыйлардан Гаишә анабыздан риваять кылынган бер хәдистә: «Корбан гаетенең беренче көнендә Аллаһы Раббүл Гыйззә хозурында корбанлык каны агызудан да сөеклерәк эш юктыр. Хисап көнендә бу хайван мөгезләре, тояклары һәм тиресе белән килеп басар. Корбанлыкның каны әле җиргә коелганчы ук, Аллаһы тарафыннан кабул ителер. Бәс, рәхәтләнеп, кинәнеп чалыгыз корбанлыкларыгызны! (Ибн Маҗәһ, Әдахи 3; Тирмизи, 1/1493).

Икенче бер хәдисне исә Әнәс (радыйәллаһу гәнһү) риваять кыла: «Мин Расүлебезнең мөгезләре сау булган аксылрак төстәге ике бәрәнне корбан итеп чалганын күрдем. Ул бер аягы белән хайванны кысып, «Бисмилләһи, Аллаһу әкбәр!» сүзләрен әйтте дә, кулындагы пычагы белән бәрәннең бугазына ышкып җибәрде» (Әхмәд бин Хәнбәл).

Барлык Ислам галимнәре корбанның диндә хупланган, изге гамәл булып, бәндәне Аллаһыга якынайта торган гыйбадәт булуы хакында уртак фикердәләр.

**2. Корбанның шәригатьтәге хөкеме**

Хәнәфи мәзһәбендә бер төбәктә даими гомер кичергән, (ягъни сәфәрдә булмаган), гает көненә тиешле нисапка тулган байлыкка ия булган хәлдә килеп ирешкән, ирекле (тоткынлыкта булмаган) мөэмин-мөселман бәндәгә елга бер мәртәбә корбанлык хайван бугазлау — вәҗиб хөкемендә. Имам Әбү Хәнифә, имам Мөхәммәд, имам Зөфәр, Хәсән һәм бер чыганакка күрә Әбү Йосыф кебек олы мөҗтәһид галимнәр корбан чалуны вәҗиб гамәл дип бәяләгәннәр.

Корбанның вәҗиб булуын раслап килгән дәлилләрнең берсе Әбү Һүрайрадән (радыйәллаһу гәнһү) килгән ошбу хәдистер: «Корбан чалырга мөмкинчелеге була торып, чалмаган кеше безнең намаз кылу урыныбызга (мәчетебезгә) якын килмәсен!» (Әхмәд бин Хәнбәл; Ибн Маҗәһ).

Әгәр дә корбан вәҗиб, ягъни мәҗбүри гамәл булмаса, аны калдыручыга бу тиклем авыр кисәтү ясалмаган булыр иде. Вәҗиб булган корбан гыйбадәте — билгеләнгән, махсус бер вакытта гына кылына торган гамәл.

Корбанның вәҗиб булуын куәтләгән тагын бер хәдистә: «Әй кешеләр! Һәрбер йорттан елга бер мәртәбә корбан чалу вәҗибтер!» — диелә. (Ибн Маҗәһ, Тирмизи).

Ибн Гомәр (радыйәллаһу гәнһү) хәзрәтләренең: «Расүлебез Мәдинәдә яшәгән ун ел дәверендә, ел саен, бер дә калдырмыйча, корбан чалып килде» сүзе дә бу карашны ныгытып килә.

Әгәр дә корбан чалырга ниятләгән мөэмин кеше корбанлык хайванны сәдака итеп кенә биреп җибәрсә (ягъни аны үзе чалмаса яки башка берәүгә кушып чалдырмаса), аның бу гамәле корбан булып саналмас. Корбан чалу хайванның канын агызу-

ны күздә тота. Чалынган малның итен тарату бик хуп күрелсә дә, мәҗбүри түгел.

### 3. Корбанның төрләре

Корбанның ике төре бар: важиб һәм нәфел.

**Важиб корбанга түбәндәгеләр керә:**

- Нәзер корбаны. Әгәр дә кеше үз-үзенә: «Ошбу дөяне яки сарыкны корбан итеп чалу минем Аллаһы алдындагы бурычым» яки «Мин бу сарыкны Аллаһы ризалыгы өчен корбан итеп чалачакмын» дисә, аңа, бай яки ярлы булуына карамастан, бу корбанны чалу важиб (мәҗбүри) була.
- Ярлы кеше тарафыннан корбан итеп чалу нияте белән сатып алынган хайван. Әгәр дә нисаб микъдарындагы байлыгы булмаган ярлы кеше корбанлыкка дип сарык сатып алса, аңа бу сарыгын корбан итеп чалу важиб була. Чөнки өстендә корбан чалу мөкәлләфияте (бурычы) булмаган ярлы адәмнең корбанлык хайван сатып алуы аның үз ихтыяры белән корбан чалырга ниятләвен аңлата. Ә бу исә нәзер буларак бәяләнә.
- Хәленнән килгән кешеләрнең Корбан гаете көннәрендә Аллаһы тәгаләгә биргән нигъмәтләре өчен шөкер итү йөзеннән, Ибраһим пәйгамбәрнең сөннәтен торгызу һәм гөнаһлардан арыну нияте белән чалынган корбаннар.
- Шөкер корбаны. Корбанның бу төре кыйран һәм тәмәттугъ хаҗы кылучыларга важибтер.
- Кәффарәт корбаны. Бу төр корбан хаҗ вакытында кылынган кайбер хата-кимчелекләргә кәффарәт буларак чалына.

**Нәфел корбаннарга исә:**

- Гакыйка корбаны. Бу корбан бала туу сөенеченнән Аллаһы тәгаләгә биргән олы нигъмәте өчен рәхмәт буларак чалына. «Гакыйка» дип яңа туган нарасыйның башындагы чәчен атыйлар. Гакыйка корбаны — Пәйгамбәребезнең сөннәте. Риваятьләргә караганда, Расүлебез (саллаллаһу гәләйһи үә сәлләм) оныгы Хөсәен дөньяга килү куанычыннан бер сарык чалган. Бу корбанны бала туган көннән алып, балигъ

булганчыга кадәр чалырга була. Шулай да, бу эшне бала туганның 7 нче, 14 нче яки 25 нче көннәрендә эшләү хәерлерәк. Ә инде иң фазыйләтлесе — 7 нче көндә. Шул ук көнне баланың чәче кыркылып, шуның авырлыгы бәрабәрендә алтыннан, көмештән яки акчалата сәдака бирү бик күркәм булыр.

- Ифрад хаҗы кылган хаҗиларның корбан чалуы. Аларга корбан чалу ваҗиб булмас, үз теләкләре белән нәфел итеп чалсалар, нур өстенә нур булыр.
- Корбан гаете көннәрендә чалынмаган корбан. Мондый корбаннар ваҗиб категориясенә кермәс, бәлки кешенең үзе теләгән вакытта Аллаһы тәгаләгә шөкер итү йөзеннән кылынган саваплы гамәл булып язылыр, иншаллаһ.

## II — КОРБАННЫҢ ШАРТЛАРЫ

### 1. Корбанның ваҗиблек шартлары

Хәнәфи мәзһәбендә, корбан гыйбадәте кешегә ваҗиб булсын өчен, аның билгеле күләмдә байлыкка ия булуы шарт. Җитәрлек матди мөмкинлекләре булмаганнарга Корбан гаете көннәрендә мал сую ваҗиб булмас. «Матди мөмкинлекләр» дигәндә, фитыр сәдакасы бирүне ваҗиб кылган байлык булу күздә тотыла. Бу байлыкны корбанның нисабы дип атыйлар. Корбан нисабы дигәндә, без кешенең зарури (асыл) ихтыяҗларыннан (торак, йорт кирәк-ярагы, транспорт, иң кирәкле кием-салым, корал, үзеңне һәм карамагыңда булганнарны бер ел дәвамында тәэмин итеп торырлык акча) һәм бурычларыннан тыш, 80 грамм алтын яки шул күләмдәге акчага ия булуын аңлыйбыз. Шулай итеп, корбан нисабына ия булган кеше хәлле дип санала һәм аңа корбан чалу ваҗиб була. Бу күләмдәге байлыгы булганнарга ел саен Корбан гаете көннәрендә мал чалу мәҗбүридер.

Зәкят белән корбанның нисаблары бер үк булса да, корбанныкында артып тору һәм бер ел узу кебек шартлар юк. Димәк,

Корбан гаете көннәрендә баеп киткән (мөлкәте нисаб микъдарына тулган) фәкыйрьгә дә корбан чалу важиб буладыр.

**2. Корбанның дөрес булуы өчен кирәкле шартлар:**

а) Корбанлык хайван сау-сәламәт, таза булырга тиеш. Малда итенең кимүенә яки саулыгын югалтуга китерерлек җитешсезлекләр булмау шарт. Шәригать галимнәре фикеренчә, дүрт төрле кимчелек хайванны корбанга чалу өчен яраксыз хәлгә китерә: сукыр булуы, аксаклык, артык арыклык һәм берәр төрле авыру. Моңа дәлил итеп Бәра бин Газиб хәзрәтләре җиткергән бер хәдис китерелә. Расүлебез (салләллаһу гәләйһи үә сәлләм) әйткән: «Корбанга чалынасы хайван дүрт төрле кимчелектән ару булырга тиеш: дөм сукырлык, аермачык беленеп торган авырулар, җелекләре корыр дәрәҗәдә арык, хәлсез булу». (Әхмәд бин Хәнбәл, Әбү Дауд, Тирмизи).

Шушыларга таянып, галимнәр кыяс (чагыштыру) юлы белән башка төрле кимчелекләрне дә билгеләгәннәр. Шул җөмләдән, хайванның бер яки ике күзенең дөм сукыр булуы, корбан чалынасы урынга мөстәкыйль рәвештә барып җитә алмас дәрәҗәдә аксак-чатан булуы, җелеге кору, күпчелек тешләренең коелган булуы, тумыштан ук колаксыз булу, җилеме киселгән булу, борыны киселгән булу, колак һәм койрыкның өчтән бер өлешеннән артыгы киселгән булу, күзләре тонык, томанлы булу һ.б. Гермафродит (ике җенесле) булган яки бары тик нәҗес, шакшы нәрсәләр белән тукланган хайваннарны корбанга чалу тыела. Шакшы нәрсәләр белән тукланган хайванны, итенең исе яхшырсын өчен, аерым урынга бикләп тоткан очракта, корбан итеп чалу рөхсәт ителә. Моның өчен дөяләрне — 40, сыер малын — 20, ә кәҗә һәм сарыкларны 10 көн бикләп тоту таләп ителә.

Мөгезләре булмаган яки сынган хайваннарны корбанга чалу ярый, чөнки бу корбан гыйбадәтенең хикмәтенә хилафлык китерерлек олы кимчелек булып саналмый. Шулай ук, печелгән хайваннарны чалу да ярый, чөнки аларның итләре тәмлерәк була. Әбү Һүрайра хәзрәтләре риваять кылган бер хәдистә: «Аллаһы рәсүле корбанга дип чалу нияте белән ике зур, симез печелгән тәкә сатып алды. Аларның берсен ул үзе

һәм гаиләсе исеменнән, ә икенчесен өммәте, ягъни Аллаһыдан гайре хак илаһ булмавын һәм Мөхәммәд галәйһиссәламнең Аның колы вә илчесе икәнлеген таныган бәндәләр исеменнән чалды» — диелә. (Ибн Маҗәһ). Симез, ләкин тире авыруларыннан интеккән малны чалу да рөхсәт ителә, чөнки тире авырулары итнең күләм һәм сыйфатына артык йогынты ясамый. Артык арык, хәлсез хайван исә корбанга бармый, чөнки ябыклык ит күләме белән турыдан-туры бәйле.

Әгәр хайван сатып алынганда таза-сау булып та, соңыннан хасталанса яки анда тора-бара корбанлык итеп чалуга комачаулык кылган кимчелекләрнең берәрсе беленсә, ике төрле юл бар: сатып алган кеше хәлле булса, яңасын алырга тиеш, инде ярлы булып моңа көче җитмәсә, шул булган хайванын, кимчелекле булса да, корбан итеп чалыр.

б) Корбан гыйбадәте махсус билгеләнгән вакытта үтәлергә тиеш. Бу вакыт — Корбан гаетенең 1 нче, 2 нче һәм 3 нче көннәрен үз эченә ала. Шушы вакыт узганнан соң корбан чалу дөрес булмас. Әлбәттә, бу эш өчен иң хәерлесе — гаетнең 1 нче көне (10 нче Зөлхиҗҗә). Гает намазы укылган шәһәрләрдә һәм авылларда корбанлыклар намаздан соң чалыныр, ә гает укылмаган төбәкләрдә — кояш чыкканнан соң. Бу — корбан чалуның башлангыч вакыты. Бу вакыт гаетнең 3 нче көнендә кояш баеганчы дәвам итә. Бәра бин Газиб (радыйәллаһу гәнһү) Расүлебез (салләллаһу гәләйһи үә сәлләм) нән түбәндәгеләрне риваять кыла: «Бу көнне (гает көнне) без иң башта бәйрәм намазын кылырга, аннан соң кайтып, корбаннарыбызны чалырга тиеш. Шулай иткән кеше сөннәтебезне тоткан булыр. Кемдә кем корбанлык хайванын бу вакыттан иртәрәк чалса, аныкы — гаиләсенә иткә дип суелган гадәти сугым гына булып калыр». (Бохари, Мөслим, Нәсаи).

Әнәс бин Мәликтән китерелгән икенче бер хәдистә исә Аллаһы рәсүле болай ди: «Кем корбанын гает намазына кадәр чалса, үзе өчен генә чалган булыр. Ә кем дә кем намаздан соң чалса, корбан йоласын үтәгән һәм мөселманнар сөннәтен тоткан булыр» (Бохари).

Корбан гыйбадәтенең өч көн белән чикләнгән булуы турында Гомәр, Гали һәм Ибн Габбас (радыяллаһү ганһүм) кебек

www.darul-kutub.com

сәхабәләр риваять кылган хәдистән укып беләбез: «Корбан чалу көннәре — өчтер, шуларның иң хәерлесе беренче көндер».

Төнге караңгылык төшкәч корбан чалу мәкруһ санала. Чөнки караңгылык аркасында хаталар китәргә мөмкин.

Корбан чалуның ваҗиблеге билгеләнгән шушы вакыт узганчы дәвам итә. Шуңа да, әгәр кеше бәйрәм көннәре башлануга кинәт баеп китсә, Ислам динен кабул итсә, коллыктан азат булса яки берәр урынга озак вакытка килеп урнашса, аңа гаетнең соңгы көне беткәнче корбан чалу ваҗиб була. Моның нәкъ киресе дә булырга мөмкин. Әгәр дә кеше гает көннәре тәмамланганчы иманыннан язса (мөртәд булса), мохтаҗлыкка төшсә (малы нисаб микъдарыннан кимесә) яки сәфәргә кузгалса, аның өстеннән корбан чалу бурычы төшеп кала. Ә инде кеше Корбан гаете көннәре узгач мохтаҗлык хәленә төшсә, корбанга яраклы сарык бәясе аның өстенә бурыч булып языла. Байлыгы булган хәлле кеше Корбан гаетенең өч көненнән берсендә корбанын чалырга өлгермичә үлеп китсә, бу бурыч аның өстеннән төшкән булып санала. Әгәр фәкыйрь кеше инде корбан чалган булып, соңыннан гает көннәре дәвамында кинәт баеп китсә, иң ышанычлы хөкем буенча, аңа яңадан корбан чалу ваҗиб була. Чөнки аның фәкыйрьлек хәлендә чалган беренче корбаны нәфел хөкемендә булып санала.

Корбан чалу эшенә гает намазы бетеп, әле хөтбә тәмамланганчы ук керешү рөхсәт ителсә дә, хөрмәт йөзеннән хөтбәнең бетүен көтү хәерлерәк.

Хаҗиларга гает көнне бәйрәм намазы уку ваҗиб түгел, чөнки алар бу вакытта хаҗ йолаларын үтәү белән мәшгуль булалар. Аларга кояш чыгу белән үк корбан чала башларга ярый.

Корбан чалу гамәле дөрес үтәлсен өчен, аны башкарган урынга да игътибар юнәлтү зарур. Әйтик, гает намазы укылмаган төбәктә шәһәр кешесе исеменнән корбан чалынганда, әлеге зат үзе әле бәйрәм намазын укымаган булса да, корбаны кабул була. Ә шул ук хәл гает намазы укылган шәһәр җирендә булса, аңлашыла ки, бу корбан дөрес булмас иде.

### 3. Кемнәргә корбан чалу ваҗиб?

Түбәндәге сыйфатларга ия булган кешегә генә корбан чалу ваҗиб буладыр:

www.darul-kutub.com

— Ислам, ягъни мөселман булу.
— Гакыл, ягъни кешенең акылга сәламәт булуы.
— Балигъ булу.
— Хөр, ягъни ирекле булу.
— Мокыйм булу, ягъни сәфәрдә булмау.
— Фитыр сәдакасы түләү өчен тиеш булган күләмдә байлыкка ия булу.

Сәфәрдәге кешегә корбан чалу вәҗиб булмаса да, ул үз теләге белән чала калса, корбаны дөрес булыр. Ләкин бу хөкем корбанлык хайван сатып алынганчы сәфәргә чыгылган булса гына урынлы. Инде корбанлыкны сатып алганнан соң сәфәргә кузгалган кешегә килсәк, аңа корбан чалмыйча, алган корбанлыгын кире сатып җибәрү тиешле.

Хатын-кыз иреннән тиешле мәһәрен алгач, хәтта ул кичектерелгән булса да, байлыкка ия булып санала һәм корбан чалырга тиеш була. Шулай ук, үз йорты булып, шунда ире белән бергә гомер кичергән хатын-кызга да, гәрчә иренең аны торак белән тәэмин итү кодрәтеннән килсә дә, корбан чалу кирәк.

Нисаб микъдарына тигез яки аннан артык малга ия булган сабый бала исеменнән дә корбан чалынырга тиеш. Җитәрлек малы булган акылы зәгыйфьрәк кешеләр бала хөкемендә карала. Чөнки Әбү Хәнифә хәзрәтләре белән имам Әбү Йосыф карашынча, балигълек яшенә ирешү һәм камил акыл корбанның вәҗиблек шартларыннан түгел. Имам Мөхәммәд исә балигълек һәм акылга бөтен булуны корбан чалу өчен кирәкле шартлар рәтенә кертеп карый. Шулай итеп, балигълеккә ирешмәгән сабыйлар һәм акылга зәгыйфь кешеләргә, җитәрлек байлыкка ия булсалар, корбан чалу тиеш булып чыга.

Вакытлыча зиһенен җуеп торганнан соң, кабат үз акылына кайткан кешенең исә хәлен исәпкә алырга кирәк. Бу кеше Корбан бәйрәме көннәрендә үз акылында булмаса, югарыда искә алынган галимнәрнең иҗтиһадларына нигезләнеп фәтва чыгарыла. Инде ул бәйрәм көннәрендә үз акылында булса, корбан чалырга тиеш була.

**4. Корбан чалу өчен яраклы хайваннар һәм аларның яше:**

www.darul-kutub.com

Ислам галимнәре бердәм рәвештә корбанлыкка кече һәм эре мөгезле терлекләр, дөяләр яраклы дигән карарга килгәннәр.

Корбанлыкка дигән сарык малының яше кимендә бер яшь булырга тиеш. Әгәр алты айлык бәрән таза-көр булып, авырлыгы бер яшьлекләрдән ким булмаса, аны да корбанга чалу рөхсәт ителә.

Бер хәдисендә Аллаһы рәсүле бу хакта: «Көчегездән килсә, бер яшен тутырып, икенче яше киткән малны гына чалырга тырышыгыз. Бер дә булмаса, алты айлык бәрән суегыз» — дип әйтеп калдырган. (Әбү Дауд, Ибн Маҗәһ, Нәсаи).

Корбанлык дөяләр кимендә биш яшьлек, ә сыер малы (монда үгезләр, буйволлар да керә) ике яшен тутырган булырга тиеш. Яше тулып җитмәгән малны чалган очракта, ул корбаннан китми. Иң хәерлесе — минималь яшь чигеннән азрак өлкәнрәк булган хайванны чалу.

Сарык малы белән кәҗәләр бер генә кеше исеменнән чалына ала. Дөя, сыер яки буйволга җиде кешегә кадәр корбан чалу нияте белән уртак булырга мөмкин. Җәбир (радыйәллаһу гәнһү) риваять кылган бер хәдистә бу хакта: «Аллаһы рәсүле корбанга дөя яки сыер чалган вакытта, бездән җиде кешегә шул малга уртак булырга боера иде», — диелә.

Икенче бер хәдистә исә, Җәбир хәзрәтләре: «Хаҗ һәм гомрә вакытларында без Аллаһы рәсүле белән корбанга дигән эре малга уртак була идек» — дип хәбәр итә. Җәбирдән: «Эре малны чалгандагы кебек, кече мөгезле терлеккә дә уртак булырга ярыймы?» — дип сорагач, ул: «Бу бары тик эре терлеккә генә кагыла» — дип җавап кайтарган.

Әгәр уртаклардан берәрсенең генә булса да өлеше 1/7 дән кимрәк икән, бу малга уртак булганнарның берсенең дә корбаны кабул булмый. Корбан җиде кешедән кабул кылынсын өчен һәрберсенең тиешле нияте булу шарт, гәрчә алар хаҗилар булып, бер-берсеннән аермалы хаҗ төрен (кыйран, тәмәттугъ) үтәсәләр дә. Җидедән азрак санда кеше дә бер малга уртак булырга мөмкин. Әгәр җиде кеше биш яки аннан да артыграк сыерга уртак булсалар, корбаннары дөрес булыр, чөнки һәрберсенә сыерларның 1/7 өлеше тия. Ләкин сигез кеше җиде

яки артыграк сандагы сыерга уртак булса, корбаннары дөрес булмас, чөнки бу очракта һәр сыер сигез өлешкә бүленеп, уртакларның һәркайсының өлеше 1/7 ким булып калыр.

Чалынган малның ите уртаклар арасында бүленгәндә, үлчәүгә салып, авырлыкка карап бүленер, гәрчә кайберәүләр үз өлешләреннән баш тарткан булса да. Корбанның ите диндә табыш китерә торган мал (тауар) категориясенә кергәнгә, аны сату-алу, алмашу яки башка берәүгә тапшыру кебек мәсьәләләр шәригать кануннары нигезендә хәл ителергә тиеш.

**5. Корбанның итенә кагылышлы шәригать хөкемнәре**

Сәләмә бин Әкъвагъдан риваять кылынган бер хәдисләрендә Расүлебез (салләллаһу гәләйһи үә сәлләм): «Корбан чалган кешенең өендә өч көн узганнан соң корбан итеннән бер кисәк тә калмасын», — дигән. Киләсе елга Аллаһы рәсүленнән шул ук мәсьәлә соралгач, ул: «Үзегез ашагыз, башкаларны сыйлагыз һәм теләгән кадәрен үзегезгә калдырыгыз. Былтыр еллар авыр килеп, кешеләр мохтаҗ булганга, аларга ярдәм итүегезне теләгән идем» — дип җавап кайтарган. (Бохари).

Корбан чалган кешегә итнең бер өлешен үзенә һәм гаиләсенең ихтыяҗларына калдырып, калганын сәдака яки бүләк рәвешендә тарату мөстәхәбтер. Сәдакага дигән өлеш итнең 1/3 нән дә ким булмаса яхшы. Ә иң хәерлесе — 1/3 ен фәкыйрь вә мохтаҗларга таратып, 1/3 ен дус-иш, күрше-күлән һәм туган-тумачаны сыйлауга тотканнан калган 1/3 ен кешенең үзенә калдыруыдыр. Корбанның итен тулаем үзеңдә калдыру да тыелмый, чөнки корбанның асылы — Аллаһы ризалыгы өчен хайванның канын коюдыр, ә итне сәдака итеп өләшү исә мөстәхәб гамәл.

Кемне дә булса карап-тәрбияләп торган фәкыйрь кешегә итне тулаем үзендә калдыру дөресрәк булыр.

Кергән акчасын сәдака итеп өләшү нияте белән корбан итен сату тыела. Шулай ук, бу ит белән зәкят түләү дә дөрес эш түгел.

# III — МАЛНЫ БУГАЗЛАУ (ЗӘБХ)

Гарәпнең «зәбх» сүзе хайванның гәүдәсе белән башы арасында сузылган муен тамырларын кисеп ташлауны аңлата. Бу гамәл — итнең хәләл булуы өчен кирәкле иң төп шартларның берсе. Шул рәвешле, нәҗес (шакшы) булып саналган кан иттән аерылган була.

**Бугазлау ысуллары**

Хайванны бугазлауның ике ысулы бар: ихтыяри (ирекле) һәм мәҗбүри.

**Ирекле (ихтыярсыз) бугазлау** дип, баш белән муен тоташкан урыннан хайванның бугазын кисүне атыйлар.

**Мәҗбүри (ихтыярсыз) бугазлау** исә, тәннең теләсә кайсы урынында җәрәхәт ясауны күздә тота. Бу чарага фәкать хайванны беренче (гадәти) ысул белән чалып булмаганда гына мөрәҗәгать итәргә ярый. Ул өстәмә (ярдәмче) ысул гына, чөнки канны агызып бетерүнең иң отышлы юлы нәкъ менә беренче ысулдыр.

Йорт хайваннары бугазны кисү юлы белән чалына. Ә кыргый җәнлекләрне исә буыннарын кисеп яки каты яралап үтерәләр. Мондый мәҗбүри чаралар ирекле бугазлауны башкарып булмаганда кулланыла.

**Чалынган мал хәләл булсын өчен ни эшләргә?**

Ирекле бугазлау процессында хайванның тын юллары, аш юлы һәм ике муен тамыры киселергә тиеш. Үбәййә бин Рифага үз бабасыннан риваять кылган бер хәдистә әйтелгәнчә, бу кеше Аллаһы рәсүленә: «Йә Расүлүллаһ! Безнең пычакларыбыз юк» — дигән. Расүлебез (салләллаһу гәләйһи үә сәлләм) аңа: «Аллаһы исемен искә алып, тырнаклар һәм тешләрдән гайре, кан агыза торган теләсә кайсы корал ярдәмендә чалынган хайванның итен ашагыз. Тырнаклар — хәбәшлеләрнең пычаклары, ә тешләр исә — сөяктер» — дип җавап биргән.

Икенче бер хәдистә исә, берәүнең сугымга дигән дөясе чыгып качкач, аның хайванны ук (сөңге) атып үтерүе турында сөйләнә. Бу хәбәрне ишеткән Аллаһы рәсүле (салләллаһу гәләйһи үә сәлләм): «Бу дөяләр арасында кыргый җәнлек кебекләре бар. Артыннан куып җитү күп көчегезне алырлык булса, аларны шулай итеп үтерегез» — дигән.

www.darulkutub.com

Югарыда әйтелгән өч әгъзаны (тын юллары, аш юлы, муен тамырлары) кисеп чыгарган очракта гына чалынган малның ите хәләл булып санала.

**Бугазлау кораллары**

Бугазлау эшен, үсеп торган тырнаклар һәм тешләрдән гайре, кан агыза торган теләсә нинди корал белән башкарырга була.

Хайванны интектермәс өчен, пычак яки башка кискеч коралны яхшылап үткенләргә кирәк. Бу хактагы бер хәдисләрендә Расүлебез (салләллаһу гәләйһи үә сәлләм) болай дигән: «Аллаһы Раббыгыз һәр эшне иң күркәм рәвештә эшләргә боерды. Әгәр үтерсәгез иң яхшы сурәттә үтерегез. (Хайван) чалсагыз, иң күркәм рәвештә чалыгыз! Берүк, пычагыгызны яхшылап кайрагыз һәм хайванны җәфаламагыз!» (Мөслим, Тирмизи, Әбү Дауд).

«Хайванны интектермәү» дигәннән, малны бугазлау урынына сыйпаштыргалап, иплән кенә алып килү; кулга яхшылап үткенләнгән пычак алып, кабаланмыйча, калтыранмыйча, ышанычлы хәрәкәтләр белән бугазын кисү күздә тотыла.

Сугымга керешкәнче, хайванга су эчерү; йөзен кыйблага каратып, сул ягына яткыру; өч аягын кушып бәйләп, арткы уң аягын ирекле калдыру сөннәт гамәлләрдәндер. Суелган мал тәмам тынганчы, тиресен туный башлау мәкруһтыр. Мал кем исеменнән чалынса, иң яхшысы шул кешенең үз куллары белән чалуыдыр. Инде үзе чалмый икән, кимендә, шунда булып, карап торуы кирәк. Әгәр корбан хатын-кыз яки балигъ булмаган бала исеменнән чалынса, аларның да чалган урында булулары хәерлерәктер.

Мал каршында пычак кайрау, бер хайванны икенчесенең күз алдында бугазлау, шулай ук корбанлыкны сугым урынына тартып-сөйрәп алып килүләр бер дә килешми торган мәкруһ гамәлләрдән санала. Шулай бервакыт, Аллаһы рәсүле берәүнең бәрән чалганын карап торган. Теге адәм малкайны җиргә егып салган да, пычагын кайрарга тотынган. Мондый таш бәгырьлелекне күргән шәфкатьле Расүлебез (салләллаһу гәләйһи үә сәлләм) аңа: «Син нәрсә, әллә хайванны берничә мәртәбә үтермәкче буласыңмы? Ул пычагыңны

www.darul-kutub.com

малны екканчы кайрап булмый идемени?» — дип шелтә ясаган. (Хәким).

Аллаһы рәсүле (салләллаһу гәләйһи үә сәлләм) йорт хайваннарын ук аткан чакта мишень буларак куллануны тыйган. Зәйд бин Әнәс бин Мәликтән риваять кылынган бер хәдистә: «Көннәрнең берсендә без бабам Әнәс бин Мәлик белән Хәкәм бин Әййүбләр йортына кердек. Шунда кешеләр җыелышып, бер читтәрәк бәйләп куелган тавыкка ук атып яталар иде. Бу тамашаны күргәч, бабам Әнәс (радыйәллаһу гәнһү): «Аллаһы рәсүле (салләллаһу гәләйһи үә сәлләм) йорт хайваннарын мишень итеп куллануны тыйды» — дип әйтте.

Ибн Гомәр хәзрәтләреннән риваять кылынган икенче бер хәдистә исә, ул Яхъя бин Сәгыйд исемле кешенең өенә килгәч, хуҗаның бер улын бәйләп куелган хәлдәге тавыкка атып яткан хәлдә күрүен хәбәр итә. Ибн Гомәр хәзрәтләре шунда ук, барып тавыкны кулына ала һәм малайны ияртеп, әтисе Яхъя янына алып килә дә: «Улыңны бу эштән тый. Мин Аллаһы рәсүленең йорт хайваннарын һәм башка барча җан ияләрен, интектереп үтерер өчен, бәйләп куюдан тыйганын ишеттем» — ди. Хәдиснең икенче версиясендә исә: «Аллаһы рәсүле хайваннарны тере килеш, тән кисәкләрен тартып-өзеп, кисеп-умырып җәфалаучыларны ләгънәт кылды», — диелә. (Бохари).

Бу хәдисләрдән без үгез сугыштыручы яки хайваннарны бер-берсенә өстереп, талатып кызык ясаучыларның ни дәрәҗәдә тыелган эш кылуларын күрәбез. Чөнки бу гамәлләрнең барысы да җан ияләрен мәгънәсезгә өзгәләү, интектерүдән башка берни түгел.

**Хайваннан кисеп алынган әгъзалар турындагы шәригать хөкемнәре:**

Хайванның терелэй кисеп яки өзеп алынган тән кисәкләре үләксә хөкемендәдер һәм аларны ашау катгый рәвештә тыелган, хәрам буладыр. Әбү Сәгыйд әл Худри хәзрәтләреннән риваять кылынган бер хәдистә әйтелгәнчә, Аллаһы рәсүленнән дөяләрнең тере килеш өркәчләрен, куй сарыкларның май җыелган койрыкларын кисеп алу турында соралгач, ул: «Тере хайваннан кисеп алынган нәрсә — үләксәдер», — дигән.

**Сугымчы (мал чалучы) да булырга тиешле шартлар:**

Чалынган малның хәләл булуы өчен кирәкле шартларның кайберләре сугымчыга кагыла. Бу кеше мөэмин-мөселман булып, **ихрам** хәлендә булмаска тиеш. Киек җанвар бугазлау өчен исә, әлеге шартларга тагын әл-Харам территориясендә (ау-сунар өчен тыелган Мәккә җирләре) булмау да өстәлә. Шуңа күрә, Мәккә җирендә тотылган киек, аучының ихрамда булу-булмавына карамастан, хәләл булмас.

Мал мөселман булмаган кеше тарафыннан чалынганда, ите хәләл булсын өчен, бу кешенең китап әһелләре (яһүди яки насара) җөмләсеннән булып, үз диненең хөкемнәрен үтәп яшәве сорала. Шулай ук, яһүди яки насараларның мал бугазлаганда Аллаһы исемен искә алулары, Аңа ширек буларак бәяләнә ала торган сүзләрдән тыелулары шарт булып тора.

Аллаһы тәгалә Коръән Кәримдә: «Бүген сезгә чиста, яхшы ашамлыклар хәләл кылынды. Шулай ук сезгә китап әһелләренең ризыгы, ә аларга сезнең ризыгыгыз хәләл булды», — дип боера. (Маидә сүрәсе, 5/5). Бу аятьтә Аллаһы тәгалә Ислам дәүләте җирләрендә (дарүл ислам) яшәгән китап әһелләре белән көфер мәмләкәтләрендә (дарүл хәрб) гомер сөргән китап әһелләре арасында, шулай ук ит белән эч мае арасында аерма куймаган. Китап әһелләренә хайванның эч маен ашау тыелган булу, аны безнең өчен харам кылмый. Шулай ук, китап әһелләре өчен харам булган хайваннар, әгәр шәригатьтә тыелмаган икән, мөселманнар өчен хәләл булып саналыр.

Хатын-кыз тарафыннан чалынган малның ите дә хәләлдер. Габдуллаһ ибн Гомәр (радыйәллаһу гәнһү) риваять кылган хәдистә әйтелгәнчә: «Бервакыт, Кәгъб ибн Мәликнең хезмәтче хатыны Сал тавы итәкләрендә хуҗасының көтүен утлатып йөргәндә, сарыкларның берсе яралана. Шунда бу хатын бер ташны чәрдәкләп, үткен ягы белән бу хайванны бугазлый. Бу хәбәр Аллаһы рәсүленә (саллаллаһу гәләйһи үә сәлләм) килеп ирешкәч, ул бу сарыкның итен ашарга боера».

«Бисмилләһ, Аллаһу әкбәр» сүзләренең мәгънәсен аңлап җиткермәгән сабый бала, исерек яки мәҗнүн (бөтенләй акылдан язган) кеше тарафыннан чалынган малның итен ашау ярамый. Акылга әзрәк зәгыйфьрәк кешенең сугымын ашау рөхсәт ителә. Телсез кеше чалган малның ите дә хәләлдер, чөнки

Аллаһы исемен кычкырып зикер итә алмау мал чалуга да, намаз кылуга да комачауламый.

Потларга, сыннарга, утка табынучы мәҗүсиләр һәм хак диннән язган мөртәдләр чалган малның итен ашау — катгый харам.

**Аллаһы исемен искә алмыйча гына суелган хайванның шәригатьтәге хөкеме:**

Аллаһы исемен телгә алмый гына чалынган малның итен ашарга ярамый. Чөнки Аллаһы тәгалә Коръәндә: «Аллаһы исеме искә алынмыйча чалынган (хайваннарның итен) ашамагыз. Чөнки бу — фискъ (бозыклык, чиктән ашу) дыр. Шайтаннар үз әшнәләренә сезнең белән көрәшсеннәр өчен коткы-вәсвәсә салалар. Әгәр аларга буйсынсагыз, мөшрикләрдән булырсыз», — дип фәрман кыла. (Әнгам сүрәсе, 6/121).

Чалганда Аллаһы исемен зикер итүне онытып калдырган кеше фасикъ булмас, бу малның ите дә хәләллеген югалтмас. Белмәү аркасында Аллаһы исемен искә алмаган кешенең хөкеме оныткан кешенеке кебектер.

Аллаһыдан гайре берәр затның (ниндидер потлар булсын, кешеләр булсын) исемен телгә алып мал чалу — катгый рәвештә тылган харамдыр. Чөнки Аллаһы тәгаләдән гайре кемгә дә булса атап корбан чалу — ширек галәмәтедер. Аллаһы тәгаләгә якынаю нияте белән корбан чалу исә — гыйбадәттер, ә гыйбадәт Аллаһыдан гайре һичкемгә кылынмас. Коръәндә Аллаһы тәгалә Расүленә болай дип боерадыр: «Әйт: «Дөреслектә, минем намазым (догам) һәм корбаным (үтәгән дини йолаларым), яшәвем һәм үлемем — барчасы да галәмнәрнең Раббысы булган Аллаһы тәгаләгә генәдер. Аның һичбер шәриге юктыр! Миңа шулай дип боерылды һәм мин мөселманнарның (бу әмергә буйсынучыларның) иң әүвәлгесемен!» (Әнгам сүрәсе, 6/162–163).

Хәзрәте Гали (радыйәллаһу гәнһү) дән риваять кылынган бер хәдистә, Расүлебез (салләллаһу гәләйһи үә сәлләм): «Аллаһы тәгалә Үзеннән башкага корбан чалган кешене ләгънәт кылды!» — дип боерадыр. (Мөслим).

Аллаһы исемен искә алу дигәндә, аның дога формасында (ягъни эндәшү-ялвару рәвешендә) булмавы шарт. Корбан

чалган вакытта, Аллаһы тәгаләнең күркәм исемнәреннән һәркайсын зикер итәргә була. Хайванны бугазлаучы кешегә ул исемнәрнең иллә дә гарәпчәсен белү кирәк түгел, шул исемнәрне үз телендә әйтү дә җитә. Ләкин бу исемнәрнең башкалар авызыннан түгел, ә корбан чалучының үзе тарафыннан әйтелүе кирәк.

**Суйганда Аллаһы исеме әйтелеп-әйтелмәве мәгълүм булмаган хайван турындагы шәригать хөкемнәре:**

Гаишә анабыздан риваять кылынган хәдистә түбәндәгеләр сөйләнә: «Берзаман сәхабәләр Расүлебез (салләллаһу гәләйһи үә сәлләм) янына килеп: «Йә Расүлүллаһ! Кайчак, әле күптән түгел генә җаһилияттә яшәгән адәмнәр ит китерәләр дә, без аның Аллаһы исемен искә алып чалынганмы, юкмы икәнен белми аптырыйбыз. Бу итләрне ашавыбыз дөресме?» — дип сораганнар. Аллаһы рәсүле (салләллаһу гәләйһи үә сәлләм) аларга: «Аллаһы исемен зикер итегез дә ашагыз!» — дип җавап кайтарган. (Бохари, Әбү Дауд, Мәлик).

Башка кеше (мөселман турында сүз бара) чалган хайванга килгәндә, ул Аллаһы исемен зикер итеп чалынган булып санала. Ягъни Аллаһы исемен кабатлап әйтү кирәк түгел. Гомумән, төгәл, ышанычлы мәгълүмат булганда гына, хайван дөрес чалынмаган дип кистереп нәтиҗә ясарга мөмкин.

**Нәзер корбаны:**

Нәзер корбаны шулай ук гыйбадәтнең бер төре булып санала. Әйткән нәзерен үтәү, бай булсын, фәкыйрь булсын — һәркем өчен важиб. Әгәр нәзер әйткән кеше бу эш өчен үзе билгеләп куйган вакытта корбанын чалмаса, аңа корбанлык хайванны сәдака итеп бирү тиеш була.

Әгәр дә хәлле кеше Корбан бәйрәме көннәрендә сарык чалырга нәзер әйткән булса, аңа ике сарык чалу важиб була: берсен нәзер корбаны буларак, икенчесен гадәти важиб корбан буларак. Инде нәзер әйткәндә үзе өчен важиб булган гадәти корбанны күздә тоткан булса, бер генә сарык чалыр, бу нәзере исә асылда нәзер булмау сәбәпле, аңа корбанның итен ашау да дөрес булыр.

Нәзер әйткән кеше тәгаенләгән вакытта (гает көннәрендә) корбан чалмаса, корбанлык хайванны тере килеш сәдака итеп

бирергә, инде чалган булса, итен таратырга тиеш була. Нәзер корбаны чалган кешегә бу малның итен ашарга ярамый. Әгәр дә инде ашаган булса, үзе ашаган микъдар итнең бәясен сәдака итеп таратырга кирәк.

Нәзер корбаны өчен хайван сатып алган кешегә аны сату тыела, чөнки аңа бу малны сатып алган мизгелдән корбан чалу ваҗиб булып төшә.

Нәзер корбаны өчен алынган хайван, гадәти ваҗиб корбанлык малга куелган шартларга ия булырга тиеш.

## IV — ҺӘДИЙ (ХАЖДА ЧАКТА ЧАЛЫНГАН КОРБАН) ҺӘМ ГАКЫЙКА (БАЛА ТУУ УҢАЕННАН ЧАЛЫНГАН КОРБАН)

**1. Һәдий — хажда чакта чалына торган корбан:**

Гарәпнең «һәдий» дигән сүзе Изге җирдә (Мәккә) Аллаһы тәгалә ризалыгы өчен гыйбадәт нияте белән чалына торган корбанлык хайваннарны аңлата. Бу сүз белән шулай ук төрле бизәкләр тагылган корбанлык хайванны Мәккәгә алып килүне дә атыйлар. Корбанлык хайваннар Мәккә җиренә гадәттә сату яки утырып йөрү өчен түгел, ә корбан итеп чалу өчен китерелә, ә өстендәге бизәкләр аның нәкъ менә шул максат өчен тәгаенләнгәнен күрсәтә.

Һәдийгә сарыклар, дөяләр һәм сыер малы яраклы. Малларны иллә дә Гарәфәт тавына китерү яки бизәү шарт түгел. Ләкин кыйран һәм тәмәттугъ хаҗы кылучылар өчен моны эшләү мәслихәт. Һәдий нияте белән, фәкать Корбан гаетендә чалына торган хайваннарны гына чалу рөхсәт ителә, чөнки бу гамәл ваҗиб корбан чалуга тиң.

**2. Гакыйка — бала туу уңаеннан чалынган корбан:**

Гакыйка — бала туу мөнәсәбәте белән чалына торган корбан. Галимнәр бу сүзнең мәгънәсе хакында ихтилафка (каршылыкка) кергәннәр. Берәүләр карашынча, «гакыйка» сүзе яңа туган баланың башындагы чәчен аңлата. Бала туу уңаеннен

чалынган хайванның «гакыйка» дип аталуы исә, аны чалган вакытта баланың чәчен кырку гадәтеннән килә диләр.

Гакыйка корбаны — нәфел гыйбадәтләргә керә. Шулай итеп, баласы туган кеше, җиденче көндә исем кушу йоласын башкарып, баланың чәчен кыркып алганнан соң, шул чәч авырлыгындагы көмеш яки алтынны, я булмаса шул күләмдәге акчаны сәдака итеп бирергә тиеш була. Чәч алган вакытка туры китереп, гакыйка корбаны чалына.

Гакыйка корбаны өчен ваҗиб корбанлыкка куелган шартларга ия булган сарык бәрәне алына. Гакыйка кыз бала өчен дә, ир бала өчен дә чалына. Малның итен кеше үзе теләгәнчә куллана ала, ягъни итне яки аннан пешерелгән ашны таратырга яраган кебек, кунаклар чакырып, сый мәҗлесе дә оештырырга була.

Әбү Муса хәзрәтләре бер хәдистә болай ди: «Балам тугач, мин аны Аллаһы рәсүле хозурына алып килдем. Расүлебез (салләллаһу гәләйһи үә сәлләм) балага Ибраһим дип исем кушты, аңкавына чәйнәлгән хөрмә җимеше сылады һәм Аллаһыдан аның өчен хәер-бәрәкәт сорады. Шуннан соң, баланы миңа кире бирде». (Бохари).

Гаишә анабыздан риваять кылынган икенче бер хәдистә исә: «Аллаһы рәсүле оныклары Хәсән вә Хөсәен өчен туганнарының җиденче көнендә корбан чалды һәм шул ук көнне исемнәрен кушты», — диелә. (Ибн Хиббан, Хәким).

**Гакыйка корбанының хикмәтләре:**

1. Безгә хәерле бала насыйп иткән Аллаһы тәгаләгә рәхмәт белдерү. Раббыбыз шөкер иткән колларына нигъмәтләрен тагын да мулрак итеп бирер.

2. Әлеге гаиләдә бала туу хакында игълан итү. Кешеләр баланың нәсел-ыруын һәм гаиләсен белсен өчен эшләнә.

3. Кешедә юмартлык һәм киң күңеллелек сыйфатларын тәрбияләп, күңелне саранлык керләреннән арындырырга ярдәм итә. Ә юмарт һәм пакь-чиста кешеләрнең бәхетле булачаклары Коръәннең үзендә әйтелә.

4. Бәйрәм сыйлары куелган табын янында җыелышкан гаилә әһелләре, туганнар һәм ярлы-ябагайлар күңелен биләп алган куаныч хисләре кешеләр арасында мәхәббәт һәм ихтирамны көчәйтеп җибәрә.

www.darul-kutub.com

**Гакыйка корбанын кем чалырга тиеш:**

Гакыйка корбаны баланың атасы, ул булмаса бабасы, ул да булмаса карт бабасы (бабасының атасы), ягъни баланы карап-тәрбияләп үстерү өчен җаваплы ир заты тарафыннан чалына. Ата кеше гакыйка корбанын үз малыннан чалырга тиеш. Балага мирас, васыять яки бүләк итү юлы белән күчкән малдан, ягъни баланың шәхси милегеннән гакыйка корбаны чалу тыела. Бу нәрсә гакыйка корбанына да, гадәти ваҗиб корбанга да кагыла.

Уйнаштан туган бала өчен гакыйка корбанын анасы чала, чөнки шәригатьтә андый баланың атасы юк булып санала.

**Гакыйка корбаны чалуның тәртибе һәм әдәпләре:**

Гакыйка корбанын бала туганның 7 нче көнендә чалу хәерлерәк. Бала кичкырын дөньяга килсә, бу көн беренче көн дип исәпләнә, ә төнлә туса, исәп иртәгесе көннән башлана. Бу корбанны кояш чыккан вакытта чалу яхшырак. Малны бугазлар алдыннан: «И Раббым! Бу корбан бары Синең ризалыгың өчен генә чалына. И Раббым! Бу хайван ... (баланың исеме әйтелә) исеменнән чалына,» — дип әйтергә кирәк.

Вак терлектән иң яхшысы булып, ваҗиб корбандагы кебек үк, кыйммәтле, ак төстәге, зур мөгезле сәламәт-таза, симез бәрән санала. Бу хайванның итен пешереп мохтаҗларга тарату тиеш. Бүлгәндә, мөмкин кадәр, сөякләрен сындырмаска, баланың да сөякләре сынмыйча, таза-сау үсүен теләргә кирәк. Хайванның сөякләрен итне ашаучы яки инде аны кабул итеп алган мохтаҗ кеше сындыра икән — зыяны юк. Кайбер галимнәр исә, гомумән дә, бүлгәндә яки эшкәрткәндә сөякләрне бөтен итеп саклап булмый икән, сындыруда артык зур проблема күрмиләр. Итне пешергәндә, баланың холкы яхшы булсын дигән нияттән, чак кына бал тамызырга киңәш ителә.

Гакыйканың арткы уң ботын пешермичә генә баланың кендек әбисенә бирү хәерле.

Итеннән шулпа пешереп, ярлы-ябагай һәм мохтаҗларны туйдыру хуплана. Бу итне хәлле кешеләргә бирү дә рөхсәт ителә. Алары исә ул итне үзләре теләгәнчә куллана ала — телиләр икән үзләре ашый, теләсәләр сата һ.б. Гакыйка корбанын чалырга нәзер әйтелгән булса, ул вакытта итне тулаем таратып бетерергә кирәк.

**Ваҗиб корбан белән гакыйка корбаны арасындагы аерма:**

Гадәти корбан белән гакыйка бер үк диярлек, тик шулай да арада кайбер аермалар бар:

1. Гакыйка итен алган хәлле кеше бу итне сатып та җибәрә ала, ә ваҗиб корбанның итен сатарга ярамый.

2. Гакыйканың итен пешкән килеш өләшү хуп күрелә, ә корбан ите чи килеш таратыла.

3. Гакыйканың арткы уң ботын пешермичә кендек әбигә бирү киңәш ителә.

4. Нәзер итеп чалынган гакыйка итенең бер өлешен чи килеш, ә калганын пешереп тарату кирәк.

5. Гакыйка нияте белән чалынган малның, хәлдән килгәнчә, сөякләрен сындырмау мөһим.

# V — ГАЕТ НАМАЗЫ НИ РӘВЕШЛЕ КЫЛЫНА?

Бәйрәмнең беренче көнендә иртән-иртүк торып, госелтәһарәтләр алып, хушбуйлар сөртенеп, матур яңа киемнәрне кияргә кирәк. Бәйрәм намазы, гадәттә, гаетнең беренче иртәсендә мәчетләрдә кылына, намазга кадәр вәгазь-хотбәләр укыла, соңыннан, кояш чыгып, якынча 40-50 минут (асылда 30 минут) узуга, намаз үзе кылына. Расүлебез (салләллаһу гәләйһи үә сәлләм) нең Корбан гаетендә сөйләгән хотбәсендә болай дип әйткәне риваять кылына: «Безнең бу көнне кылган беренче гамәлебез — намаз булыр. Соңыннан корбанлыкларыбызны бугазларбыз. Бу рәвешле эшләгәнегез, һичшиксез, минем сөннәтемә туры китереп гамәл кылган булыр». (Бохари, Гыйдәйн, 3).

Хәнәфи мәзһәбендә ике рәкәкатьтән торган гает намазы — ваҗиб хөкемендә, шәфигыйларда исә — сөннәт.

Безнең мәзһәб буенча, үз акылында булган, балигълек яшенә җиткән, сау-сәламәт, ирекле һәм сәфәрдә булмаган һәр ир-атка гает намазын кылу — ваҗиб.

Бәйрәм намазлары җәмәгать белән кылына һәм ике рәкәгатьтән тора. Намаз вакыты җитүгә, имам азан вә камәт

әйтмичә генә бәйрәм намазы кылуга ният итә. Җәмәгать тә, аңа ияреп ният кыла. Гает намазлары мәчетләрдә яки махсус ясалган намаз кылу мәйданнарында укыла, ялгыз кылынмый.

**Бәйрәм намазының кылыну рәвеше:**

Имам кычкырып «Аллаһу әкбәр» сүзен әйтеп тәкбир китерә дә, кулларын кендек астына куеп бәйли. Аңа ияреп җәмәгать тә эчтән генә тәкбир китерә. Соңыннан, имам да, җәмәгать тә үз эчләреннән «Сөбханәкә» догасын укыйлар. Дога тәмам булгач, имам да, җәмәгать тә өч мәртәбә тәкбир әйтәләр, һәркайсында кулларын колак турына күтәреп, яңадан аска төшерәләр. Өченче тәкбирдән соң куллар кендек астына куеп бәйләнә. Тәкбирләр арасында кыска гына пауза ясала. Моннан соң, имам кычкырып «Фатиха» сүрәсен һәм тагын бер өстәмә сүрә укый, бу вакытта җәмәгать тын гына тыңлап басып тора. Соңрак, рөкугъка кителә һәм ике сәҗдә кылынып, беренче рәкәгать тәмам була.

Икенче рәкәгатькә торып баскач, имам янә кычкырып «Фатиха» белән бер өстәмә сүрә укый. Аннан соң, беренче рәкәгатьтәге кебек кулларны бер күтәреп, бер төшереп өч мәртәбә тәкбир әйтелә. Өченче тәкбирдән соң рөкугъка кителә. Алга таба ике сәҗдә кылынып, «Әттәхият», «Салават»лар укылганнан соң, ике якка сәлам бирелә.

Намаз укылып беткәч, имам мөнбәргә менеп хотбә сөйли. Хотбәдә гадәттә бәйрәмнең кешеләрне берләштерүче, татулаштыручы, ярдәмләшүгә этәрүче форсат булуы турында әйтелә.

Хотбә тәмам булгач, халык корбан чалырга таралыша.

www.darulkutub.com

# ЭЧТӘЛЕК


МӨКАДДИМӘ ..... 3

КОРБАННЫҢ МӘГЪНӘСЕ ҺӘМ ТАРИХЫ КОРБАННЫҢ ХИКМӘТЕ ҺӘМ ФАЙДАЛАРЫ ..... 6

1. Халык арасында бердәмлек һәм ярдәмләшү хисләрен көчәйтә ..... 6

2. Корбан гыйбадәте адәм баласын Раббысына якынайта. 6

3. Корбан — кешенең тәкъвалык билгесе ..... 6

4. Корбан гыйбадәте безгә Аллаһы боерыгына буйсынуның Ибраһим һәм Исмәгыйль пәйгамбәрләр тормышында дастани югарылыкка ирешкән мисалын искәртә ..... 7

5. Корбан — Аллаһы биргән исәпсез-хисапсыз нигъмәтләргә шөкер итү билгесе ..... 8

6. Корбан — гөнаһлардан арыну һәм гыйбадәтне кимчелекләрдән пакьләү чарасы ..... 8

I — КОРБАН СҮЗЕНЕҢ МӘГЪНӘСЕ, КОРБАННЫҢ ШӘРИГАТЬТӘГЕ ХӨКЕМЕ ҺӘМ АҢА КАГЫЛЫШЛЫ КАЙБЕР ФИКЪҺИ МӘСЬӘЛӘЛӘР ..... 9

1. «Корбан» сүзенең мәгънәсе һәм шәригатьтәге хөкеме ... 9

2. Корбанның шәригатьтәге хөкеме ..... 10

3. Корбанның төрләре ..... 11

II — КОРБАННЫҢ ШАРТЛАРЫ ..... 12

1. Корбанның ваҗиблек шартлары ..... 12

2. Корбанның дөрес булуы өчен кирәкле шартлар ..... 13

3. Кемнәргә корбан чалу ваҗиб? ..... 15

4. Корбан чалу өчен яраклы хайваннар һәм аларның яше. 16

5. Корбанның итенә кагылышлы шәригать хөкемнәре ..... 18

III — МАЛНЫ БУГАЗЛАУ (ЗӘБХ) ..... 19

Бугазлау ысуллары ..... 19

Чалынган мал хәләл булсын өчен ни эшләргә? ..... 19

Бугазлау кораллары ..... 20


www.qarui.kutub.com

Хайваннан кисеп алынган әгъзалар турындагы шәригать хөкемнәре.....21
Сугымчы (мал чалучы) да булырга тиешле шартлар.....21
Аллаһы исемен искә алмыйча гына суелган хайванның шәригатьтәге хөкеме.....23
Суйганда Аллаһы исеме әйтелеп-әйтелмәве мәгълүм булмаган хайван турындагы шәригать хөкемнәре.....24
Нәзер корбаны.....24

IV — ҺӘДИЙ (ХАЖДА ЧАКТА ЧАЛЫНГАН КОРБАН) ҺӘМ ГАКЫЙКА (БАЛА ТУУ УҢАЕННАН ЧАЛЫНГАН КОРБАН).....25
1. Һәдий — хажда чакта чалына торган корбан.....25
2. Гакыйка — бала туу уңаеннан чалынган корбан.....25
Гакыйка корбанының хикмәтләре.....26
Гакыйка корбанын кем чалырга тиеш.....27
Гакыйка корбаны чалуның тәртибе һәм әдәпләре.....27
Важиб корбан белән гакыйка корбаны арасындагы аерма.....28

V — ГАЕТ НАМАЗЫ НИ РӘВЕШЛЕ КЫЛЫНА?.....28

ЭЧТӘЛЕК.....30

www.darul-kutub.com

www.darul-kutub.com